Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.01.2025 г. Менделеевск № 4

Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсенең “10 нчы төзәтү колониясе” федераль казна учреждениесе хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә туклану өчен ата-ана взносларын түләүдән азат итү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсенең “10 нчы төзәтү колониясе” федераль казна учреждениесе бүлеге хезмәткәрләренең гаиләләренә адреслы социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ

1. Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсенең “10 нчы төзәтү колониясе” федераль казна учреждениесе бүлеге хезмәткәрләре балаларына Менделеевск муниципаль районы учреждениеләрендә мәктәпкәчә белем бирү программаларын, Менделеевск муниципаль районы учреждениеләрендә төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Менделеевск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә 2025 елның 1 гыйнвареннан 2025 елның 31 декабренә кадәр туклану өчен түләүдән азат итәргә.
2. Менделеевск муниципаль районы финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсенең “10 нчы төзәтү колониясе” федераль казна учреждениесе бүлеге хезмәткәрләре балаларына Менделеевск муниципаль районы учреждениеләрендә мәктәпкәчә белем бирү программаларын, Менделеевск муниципаль районы учреждениеләрендә төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Менделеевск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә туклану өчен финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми

сайтында: https://mendeleevsk.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Ю.М.Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров